СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

16 июль, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 77 (8089) | Бәясе билгеләнгәнчә

## Аяз сәгатьләр дә санаулы

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Алдан аяк киенгән хуҗалыклар күпъеллык үләннәрнең беренче катыннан коры печәнне ярыйсы гына туплап калдылар. Мичурин исемендәге хуҗалык аны 1300 тонна күләмендә җыеп эскертләде. Бу - планның 80 проценты. «Якты Күл»дә бу төр план үтәлеше 83 процент тирәсе. Ә Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта печән әзерләү планы тула язды.

Ә бүген төп игътибар беръеллык үләннәрдән сенаж салуга юнәлдерелергә тиеш. Кызганычка каршы, бу эшнең темпы һич тә канәгатьләндерерлек түгел әле. Әйтик, соңгы биш көндә фәкать 3 мең тоннадан артыграк кына сенаж салынды. Мичурин исемендәге, «Таң», «Кондырча», Муса Җәлил исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда сенаж салуны ярыйсы ук эзлекле алып баралар. Печән әзерләүдә алдынгы булган җәлилләләр эшнең монысында да оешканлык күрсәттеләр һәм сусыл азыкны планның яртысы чамасында хәстәрләп куйдылар инде. Шуңа да бүген аларда бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлегә 11 центнерга җитте. Ә менә шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында, «Родина», «Игенче», «Алга», «Үрнәк», «Заря» хуҗалыкларында сенаж базлары буп - буш әле. Хафизов исемендәге, «Заветы Ильича», «Комбайн», «Әлмәт», «Якты Күл», «Рассвет» хуҗалыкларында да бу эштә бик ашыкмыйлар. Шуңа да аларның кайсыларында бер шартлы терлеккә әзерләнгән азык берәмлегә 2 - 3 центнерга гына җыела.

Сенаж салуның акрын баруын кайбер урыннарда көннәрнең яңгырлы торуы белән акларга тырышалар һәм моның белән килешмичә дә булмый. Әмма төп сәбәп - техниканың җитештерүчәнлеге түбән булу. Шулай булмаганда, күп хуҗалыкларда витаминлы үлән оны ясау агрегатларының да тик торуын нәрсә белән аңлатырга ди соң? Бу эш белән хәзер чынлап торып «Кондырча», Синдряков исемендәге, Мичурин исемендәге, «Родина» хуҗалыкларында гына шөгыльләнәләр. Синдряковлылар бу төр азыкны, мичуринлылар кебек үк заданиедән тыш әзерлиләр инде.

Чалт аяз көннәрнең шактыен кулдан ычкындырганбыз икән, инде аяз сәгатьләрне файдалану турында кайгыртырга калды. Уракка чыкканчы беръеллык үләннәрне җыйнап алмасак, бик авырга киләсе.

## ЭШ АГАЧЫ ҺӘРВАКЫТТА БИК ЮМАРТ КИТЕРЕР ҖИМЕШ

Валерий Алексеевич тормышындагы быелгы датаны билгеләп үттеме, юкмы, анысы безгә мәгълүм түгел, әмма машина руле артына утырып эшли башлавына өч дистә ел тулу эзсез генә узып китәрлек вакыйга түгелдер инде ул. Нәкъ менә 1967 нче елда башлана бит аның шоферлык стажы. Соңгы 18 елын «Татнефть» подразделениеләрендә эшли. Шуның 16 елын - Норлат автоюллар төзү идарәсендә. Башта «Татра» йөртте ул, соңрак үзбушаткыч «КамАЗ»га күчеп утырды. Махсус наряд бирелмәсә дә, Валерий Алексеевич белә: ул һәрчак юл төзүчеләр, ремонтлаучылар янында булырга тиеш. Асфальт - бетон заводыннан юлга асфальт - бетон катнашмасы һәм инерт материаллар ташый ул. Коллективта аны хезмәт сөючән, карусыз булганы өчен хөрмәт итәләр.



Рәсемдә: НУАД шоферы В.Сапожников.
Н.КВАШНИНА ФОТОСЫ.

## Районыбыз хәбәрләр тормышыннан

### Активлыкны киметмиләр

572 килограмм. Кычытканлы җирле үзидарә Советында ярты елда бер сыер башына әзерләнгән сөт шулкадәр булды. Былтыргы күрсәткечне дә ике ярым тапкырга узып китеп, ярты еллык заданиене 160 процентка үтәделәр бирелә. Сөт җыюны җиренә җиткереп оештыргач һәм түләү мәсьәләсен дә игътибар үзәгендә тоткач, авыл халкы үз ихтыяҗларыннан арткан сөтне дәүләткә сатуда бүген дә активлыгын киметми - бирелән хәзерләүләр пунктына көн саен бер тонна чамасы сөт китерелә.

### Яңа бинада эшләве дә кызык

Күптән түгел Норлат станциясенең товар конторасы яңа административ бинада өй туе үткәрде. Элек кечкенә генә иске йортта урнашып, кысанлыктан интеккән товар конторасы хезмәткәрләрен хуҗалыкара төзелеш оешмасының 547 нче ПМКсы яңа ике катлы бинага кертте. Конторада 18 ләп кеше. Норлат станциясенең рәсми эшләрен тулысынча диярлек алар җитәкли һәм башкара. Төзүчеләргә карата да алар канәгатьлекләрен белдерәләр.

## Оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр, КХА һәм җирле үзидарә Советлары рәисләре игътибарына!

Шәһәрнең һәм торак пунктларның төзеклеген һәм чисталыгын планлы тикшерү вакытында урамнарның чүплелеге, бу җәһәттән социаль - культура объектларының да канәгатьләнмәслек торышы билгеләнде.

Шул уңайдан табигатьне һәм әйләнә - тирә мохитны саклау инспекциясе кисәтә һәм предписание бирә:

1. Бу предписание басылганнан соң өч көн эчендә территорияләрегезне тиешле тәртипкә китерергә.

2. Һәр җомга көнне территорияләрне җыю чарасын күрергә.

Предписание үтәлмәгән очракта, җаваплы кешеләргә карата административ тәртиптә штраф салыначак.

**Р.МОРАДЫЙМОВ,**
**табигатьне һәм әйләнә - тирә мохитны саклау буенча Дәүләт инспекторы.**

## Абзарлар яңара

Тимерлектәге товарлыклы - дуңгызчылык абзарлары күптән ремонт көтә иде инде. Ниһаять, быел аларны төзәтү, реконструкцияләү эшенә чын - чынлап алындылар. Элегрәк 250 - 300 баш мал симертелгән абзарга тулысынча реконструкция үткәрелә. Киләчәктә бу бинада ана дуңгызлар асралачак.

Ана дуңгызлар тотыла торган бинада исә ремонтның агымдагысын үткәрү планлаштырылган.

Халык теленә түбәндәге абзар буларак кергән бинада да ремонт эшләре киң колач белән бара бүген.

Реконструкция, ремонт эшләрен РСУ төзүчеләре башкара.

## Җыр сөючеләр, милли сәнгатебезгә табынучылар игътибарына!

19 июль көнне шәһәрнең үзәк стадионында Татарстан Мәдәният министрлыгы, Габдулла Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе, Кол Шәриф мәчете фонды тарафыннан оештырылган Кол Шәриф мәчетен яңадан төзү өчен сәнгать осталарының «Иманыбызга кайтыйк» дип исемләнгән матди ярдәм концерты була. **Җыенда Татарстанның сәнгать осталары Хәния Фәрхи - Биктаһир, Асаф Вәлиев, Габделфәт Сафин, Рөстәм Закиров, Эльвира Хәйруллина, Лидия Әхмәтова, Зөлфия Шакирова һ.б., «Бәйрәм», «Болгар кызлары», «Алтын ай», «Исхак Хан» ансамбльләре, Татарстанның халык артисты Фердинант Гыймадиев җитәкчелегендәге бию төркеме катнашачак.**

Моннан тыш республика районнарыннан махсус чакырылган яшь җырчылар, кунакка танылып өлгергән яшь җыр осталары, танылган музыкант - композиторлар да киләчәк.

Концертны Җәвит Шакиров һәм Флера Шәрипова алып бара.

**Җыен 18.30 сәг.тә башланачак, ул бушлай була.**

Бәйрәмгә рәхим итегез!

## Хәбәрләр Хәбәрләр Хәбәрләр

Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы нигезендә Татарстан Республикасында химия фәнен алга таба үстерү, фосфорорганик химия өлкәсендәге күренекле фәнни ачышлары һәм уйлап табулары өчен галимнәрне бүләкләү, академиклар А.Е.Арбузов һәм Б.А.Арбузов истәлекләрен мәңгеләштерү максатында фосфорорганик химия өлкәсендә ике елга бер тапкыр бирелә торган халыкара Арбузов бүләге булдырылды. Фосфорорганик химия өлкәсендә Халыкара Арбузов бүләгенә лаек булган затларга «Фосфорорганик химия өлкәсендә Халыкара Арбузов бүләге лауреаты» дигән исем бирелә. Халыкара Арбузов бүләге лауреатлары өчен истәлекле медаль һәм диплом булдырыла.

***

Татарстан коммунистлар партиясе пленумында Ирек мәйданындагы Ленин һәйкәлен сүтүгә өндәгән җәмәгать хәрәкәтләренә мөнәсәбәтле карар кабул ителде. Анда болай диелә: «Мондый ниятkә килергә берниндн төпле сәбәп тә юк. Ленинның 1920 елда Татарстан дәүләтчелеген торгызуга куйган көчен берничек тә инкарь итеп булмый. Ленин Көнчыгышның зыялы халыкларына, шул исәптән татарларга да әхлакый тәрбия үрнәге булды һәм хәзер дә шулай. Аның эшчәнлеге Азиядә милли-азатлык көрәшен күтәрүдә, колониализм системасын җимерүдә ныклы таяныч булды. В.И.Ленинның исемен пычратырга, аның тарихи истәлеген югалтырга омтылу - бу аның көндәшләренең томаналыгыннан гына килә.»

# «КЕЛӘТЛӘР ДӘ, КҮҢЕЛЛӘР ДӘ КИҢ»

## ЭЛЕВАТОРДА ЯҢА УҢЫШ АШЛЫГЫН КӨТӘЛӘР

***Быел Норлат - Октябрь элеваторының матди - техник базасының яңа сезонга әзерлегән дәүләт кабул итүе елдагыдан иртәрәк уздырылса да, абруйлы комиссия предприятиенең әзерлеген «яхшы» билгесе белән бәяләде.***

Быел ашлык кабул итү сезонының башка еллардагыдан үзгәрәк булачагы инде алдан ук билгеле иде һәм элеватор коллективы район хуҗалыкларыннан ашлыкның елдагыдан күпкә мулрак килергә тиешлеген дә, һава шартлары соңгы вакытлардагыча яңгырлы торса ашлыкның дымлылыгы югары буласын да уйлап эш иткән. Быел бодайның елдагыдан күп буласын күздә тотып элеваторның беренче участогындагы (аны үзара иске элеватор дип йөртәләр) алтынчы вышканы шушы культураны кабул итәргә әзерләгәннәр, соңгы елларда бик кирәге чыкмаган өченче вышканы да, икенче дворның әлегә хәтле рәтләп эшләтелмәгән җир асты транспортерларын да төзәтеп сафка бастырганнар быел. Өске транспортерлар уза торган урыннардагы агач конструкцияләр металлга алыштырылган. Сүз уңаеннан әйткәндә, комиссия һәр транспортерны, һәр күтәрткечне эшләтеп күрсәткәннән соң гына кабул итте быел. Ә гомуми озынлыклары берничә чакрымга җыела торган ул транспортерларның көйле эшләп торуы килгән бер машинаны бушатып, ашлыгын тиз арада билгеләнгән складка урнаштыру өчен никадәр әһәмиятле икәнлеген шушы эшне үз башларыннан кичергән кешеләр генә белә. Ә элеватор коллективында гомерләрендә дистәләрчә сезон рәттән ашлык кабул итүдә катнашкан кешеләр, үз эшләренең чын осталары булган белгечләр аз түгел. Нәкъ менә эш рәтен белә торган шундый кешеләрнең биредә «басылып» эшләвенә ирешү өчен предприятие җитәкчелеге кулыннан килгән бар чараны да күрә. Шушында эшләп лаеклы ялга чыккан аксакаллар да кызу эш өстендә коллективны ярдәмнәреннән ташламыйлар, җитәкчелекнең сүзен аяк астына салмыйлар. Гомере буе ашлык киптерүче өлкән мастер булган ветеран Николай Андреевич Мокеев быелгы ремонтта да җиң сызганып булышкан, ашлык кабул итү чорында да читтә калмаячак. Икенче дворның гомерлек хуҗасы булган һәм хәзер лаеклы ялдагы Габдулла Зыятдинович Гафуров та өендә утырмый бу кызу чорда.

Зур матди һәм финанс кыенлыклары шартларында барган ремонт эшләрен, әйткәнебезчә, нигездә предприятиенең зур тәҗрибәле үз эшчеләре башкарып чыккан. Бигрәк тә эретеп ябыштыручыларга эш күп булган быел. Яңа элеваторда ике ай буена алар кулы белән ямалган, ныгытылган металл конструкцияләрне санап кына да бетерерлек түгел. Ашлык салына торган складларны тиешле тәртипкә китерүгә исә участоклардагы һәркемнең өлеше кергән. Шуның нәтиҗәсе буларак, комиссия барлык складларның да ашлыкны коры мәйданчыкларга салып, кызмасынга актив җилләтеп тору өчен бөтенесе дә эшләнгән булуын билгеләп үтте. Һава йөргечләрнең төрле вариантларын кулланып карап, иң уңайлысын һәм бәрәкәтлесен файдаланырга тырышалар. Бары тик икенче дворда гына җилләткечләрнең әлегә кирәк кадәр санда булмавы күзгә ташлана. Коры елны аларны бер складтан икенчесенә күчереп йөртеп тә була анысы, әмма ел яңгырлы килсә хәл катлауланырга мөмкин.

Бу урында инде элеватор эшчәнлегендә гаять мөһим буыннардан булган ашлык киптергечләр турында аерым әйтеп китәргә кирәктер. Биредә алар алтау һәм тулы куәткә эшләгәндә барысы бергә сәгатенә 226 планлы тонна ашлык киптерергә мөмкин. Һәм киптерү агрегатлары хуҗалары аларны нәкъ менә шулай тулы куәткә эшли алырлык иттерү өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләгәннәр быел. Арада иң куәтлеләрдән булган 1 нче киптергечкә капиталь ремонт ясалып, башкалары да энә күзеннән үткәрелгән. Бу уңайдан элеватор җитәкчелеге киптерүчеләр Иван Малков, Павел Никифоров, Әхәт Сәгыйров, Минһадый Вәлиев, Зөфәр Хәйретдинов, Минсәлим Ногъмановның зур тырышлык куйганлыкларын билгеләп әйтә. Анысы хактыр да, чөнки ашлык киптерүчеләрнең дәүләт комиссиясен үз карамакларындагы участокларның ышанычлы булуына инанган хәлдә тыныч күңел белән каршы алулары юкка булмагандыр. Һәм һәр киптергечне кабызып карау аларның сезонга әзер булганлыгына ышандырды.

Киптергечләрнең инде бүгеннән кабызырлык икәнлеге куандырса да, аларны ягулык белән тәэмин итү мәсьәләсенең никадәр катлаулы булачагы борчылырлык. Әле аның нормаль елда да кирәк кадәр ягулыгын юнәтү зур проблема булып тора, ә ел яңгырлы килгән тәкъдирдә алда телгән алынган планлы тонналар саны берничә тапкырга артыграк булачак, димәк, ягулык та шулкадәр үк күбрәк сарыф ителәчәк бит. Һәм бу очракта ягулык юнәтү мәшәкате бер элеватор җитәкчелеге җилкәсендә генә калмас дип уйлыйбыз. Предприятие коллективына быелгы сезонда болай да борчу - мәшәкатьләр аз булмас төсле әле. Ник дигәндә, кабул ителә торган ашлыкка быелдан яңа дәүләт стандартлары кертелә һәм аларның төгәл үтәлешенә ирешү бер дә җиңел генә булмаячак. Дөрес, элеваторның Рәмзия Зарипова җитәкчелегендәге лабораториясе коллективы яңа сезонга бүгеннән әзер инде: ашлыкны барлык параметрлар буенча да анализлап, машиналарны тоткарлыксыз үткәрү өчен кызлар зур тырышлык куйганнар. Әмма аларның җитез эшләве хуҗалыклардагы агрономнарның, амбар хуҗалыгы хезмәткәрләренең үз вазифаларына ни дәрәҗәдә җаваплы каравына да бәйле булачак. Сүз элеваторга озатыла торган һәр машина ашлыкны тиешле документлар белән юллау турында бара. Сорт, чүплелек, җилемсә дәрәҗәсе мәсьәләләрендә бәхәс чыкмасын дисәк, һәр культураның һәр йөгенә документлар җиренә җиткерелеп тутырылган булырга тиеш.

Әлбәттә, болар хакында конкрет эшкә тотынгач та сүз булачак әле. Әмма алдан искә төшереп куюның да зыяны юк. Элеватор коллективы да кабул итү сезонының гаять киеренке чорларында төрле катлаулылыклар да килеп чыгарга мөмкин булуын яхшы аңлый. Әмма Полина Просвиркина, Радик Сибгатуллин, Вәзыйх Гаффаров җитәкчелегендәге өч участок коллективы да бүгенгә яңа сезонга әзерләнүнең үз кулларыннан килгәнен нигездә башкарып, вак - төяк кимчелекләрне тиз арада бетерү чараларын күрә. Ил байлыгы икмәк язмышы өчен җаваплылыкны үз кулларына алачак кешеләрнең складлары иркен, күңелләре киң.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

## КАНИКУЛЛАР ДӘВАМ ИТӘ

Мәктәп укучылары каникулларда бүген. Район мәгариф бүлеге мәктәпләр, педагогия коллективлары алдына аларны балалар өчен файдалы да, нәтиҗәле дә итеп үткәрүне максат иткәннәр иде. Әйтергә кирәк, каникуллар нигездә зур оешканлык белән бара. Июнь аенда гына да мәгариф бүлеге каршындагы «Яшүсмер» профиль лагеренда 270ләп бала ял итәргә өлгерде. Бөтен яклап әйбәт оештырылды ул.



Шәһәр мәктәпләре каршындагы ял лагерьларында исә бер айда 453 бала ял итте.

Дөрес, шикәр заводының «Заречный» лагере быел озак балалар кабул итә алмый торды. Аның каравы соңлап булса да җәйнең беренче аенда биредә күләмле ремонт эшләре үткәрелде. Хәзер лагерьда 140 бала ял итә.

Шөкер, быел авыл мәктәпләре каршында хезмәт һәм ял лагерьларының эшен июнь башында ук оештыра алдык. Бүгенге көндә шундый балалар ялы урыннары районның 39 мәктәбе каршында эшли. Бу көннәрдә аларда балаларның ялы һәм хезмәте ничек оештырылуын тикшерү максатында мәктәпләрдә дә булырга туры килде. Каравыл Тавы, Егоркино мәктәпләрендә булганда шатланып кайттык: әлеге учреждениеләрнең һәр икесендә лагерьларга даими рәвештә 20 - 30 бала йөри икән. Тукланy оештырылган. Бу җәһәттән мәктәп коллективларына база хуҗалыклары да зур ярдәм күрсәтә. Мәктәп педагоглары укучылар өчен эш тә тапканнар, шул ук вакытта буш вакытларын файдалы итеп үткәрү өчен чараларны да байтак үткәрәләр. Әле параллель рәвештә мәктәпкә ремонт үткәрергә дә өлгерәләр. Биләр Озеро, Кизләү, Яңа Иглай, Югары Норлат мәктәпләрендә дә балалар ялы файдалы, нәтиҗәле уза дигән фикергә килдек без. Ә менә Кәкре Атау, Төрнәс, Богдашкино мәктәпләре каршындагы лагерьларга балалар йөрсә дә, аларны тукландыру мәсьәләсе авыр хәл ителә. Моны база хуҗалыкларының иртәгә һәм якын киләчәктә үз басуларында, фермаларында эшләячәк кешеләргә мөнәсәбәт шул дәрәҗәдә генә дип аңларга инде.

Гомумән, соңгы берничә көн эчендә 15ләп мәктәптә булып бер генә җирдә - Чулпан мәктәбендә генә балалар ялының начар оештырылуына канәгатьсезлек күрсәтергә туры килде безгә. Лагерь оештырылган дисәләр дә, биредәге мәктәп яны участогында балаларның эшләгәне күренми: бакчаны чүп басып киткән, шул сәбәпле яшелчә, җиләк - җимеш начар үсә. Участокның коймалары сындырылып бетерелгән. Шунда бөтен авыл кәҗә - сарыгы йөргәч, җимеш агачлары да үсеп, «исәеп» китә алмый. Мәктәптә буяу исе дә аңкымау биредә эчке ремонт эшенең дә шул дәрәҗәдә генә булуы турында сөйли.

Календарьда - июль. Каникуллар тәмамланыр көннәргә әле шактый вакыт бар. Аларны ахыргача яхшы итеп уздырасы иде. Сүз бит балаларыбыз, киләчәк буын турында бара.

**Г.ӘҺЛИУЛЛИНА,**
**район мәгариф бүлегенең тәрбия эше өчен җаваплы методисты.**




РСУның Козлов исемендәге ярдәмче хуҗалыгы механизаторлары арасында берьюлы берничә техникада эшләмәгән кеше аз. Валерий Воспенников, мәсәлән, теләсә нинди марка техниканы иярли ала. Шуңа да кирәк булганда җиңел автомашина йөртә ул, ихтыяҗ туганда «КамАЗ»га утыртып ерак юлга да җибәрәләр үзен. Быел язгы чәчү чорында трактор рычагы артына да утырып эшләде әле. Сөт ташый торган техника да Валерийга беркетелгән.

Иң мөһиме, егет аларның һәркайсын оста йөртә, производствоның кайсы участогына эшкә җибәрсәләр, шунда тырышып эшли.

**Рәсемдә: В.Воспенников.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# ЯЗМЫШЛАРДА - ГОМЕР СЫНАУЛАРЫ

Медицина хезмәткәрләре көненең соңгысында шифаханә җитәкчелеге, хезмәттәшләре котлавыннан күңеле тулды Рәшит Әбелгатовичның. Ни дисәң дә, быел аңа да 60 яшь тула бит. Кайчак үткән гомерен күз алдыннан кичерә дә, күңеле нечкәреп китә.



Барысы да яхшы хәтердә: алтмышынчы еллар башында Казанда медицина училищесының теш - техник бүлеген тәмамлаган Әлмәт районы егетен район үзәк шифаханәсендә колач җәеп каршылаганнар иде. Төз гәүдәле, искиткеч чибәр, интеллегентлы, йөрәге эшкә ашкынып тора. Кулында - диплом, әле аның да гадәтие түгел - кызыл тышлысы. Янәшәдә үзе кебек үк чибәр хатыны Роза.

Ул вакытта алты почмаклы иске агач йортның ике бүлмәсендә эшлиләр иде теш табиблары. Бер стоматолог, бер техникка халык берничә көн алдан чиратка язылып кына эләгә алды. Рәшит тә теш технигы булып эшли башлады. Училищеда алган теоретик белемне бөтенләе белән практикада куллану теләге зур иде егеттә.

Мостафиннарның тормышлары әллә ни көйләнмәгән булса да, гаилә канәгатьләнә бел-де. Уллары Ринат туу исә яшәешне тагын да баетып, эчтәлеклерәк итеп җибәрде. Озак та үтмәде, Рәшитне җирле комитет рәисе итеп сайладылар: кеше дип өзелүе, гадел булуы нигез итеп алынгандыр, мөгаен. Төп эше дә көйле барды. Бүлеккә мөрәҗәгать иткән һәр кешенең үтенечен канәгатьләндерүгә омтылуы, вакыт белән санашмавы нәтиҗәсендә халык ихтирамын да яулады ул. Шулай да укуын дәвам иттерергә теләге зур иде Рәшитнең һәм ул институтка керергә карар кылды.

- Шул вакытта хатынымның аз гына каршы төшүе дә миңа бу адымны ясауга зур киртә булыр иде,- ди Рәшит Әбелгатович ул вакытларны искә алып - минем белем алуымда, кеше булып формалашуымда, гомумән, һәрнәрсәдә Розаның йогынтысы зур булды...

1964 нче елда Рәшит Казан дәүләт медицина студенты иде инде. Баштарак гаиләсеннән аерым яшәде ул: беренче курстан соң хатыны белән улын да үз янына алдырды. Кеше өстендә яшәргә туры килсә дә, гаилә бәхетле иде. Өстәвенә, Розага да эш табылды: совет сәүдәсе институтын тәмамлаган белгечне Казан кооператив техникумына эшкә ике куллап алдылар.

Җитмешенче елда кулына югары белемле белгеч дипломы алган Р.Мостафинны район җитәкчелеге яңадан Норлатка соратып кайтарды. Халык вакытлыча «югалып»торган табибын онытмаган икән: теш суырту, дәвалау, куйдыру белән кем генә дә, кайдан гына мөрәҗәгать итми иде аңа. Әмма Рәшит Әбелгатовичка бары тик стоматология эше белән озак шөгыльләнергә туры килмәде: берничә елдан баш табиб урынбасары итеп билгеләнде. Параллель рәвештә теш табиблыгы эшен дә дәвам итте. Яхшы оештыручы, белемле белгеч, кеше җаена бару, хәленә керешү, итәгатьлелек - бу кешегә хас иң төп сыйфатлар шулар. Ә инде табиб буларак тоткан дәрәҗәсе дистәләрчә еллар буена бер генә дә төшмәде, ак халаты тапланмады.

Сиксәненче еллар уртасында ук аның районда беренчеләрдән булып, югары категориягә ия булуы, «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнүе, «Татарстан Республикасы атказанган табибы» исеменә тәкъдим ителүе дә шул хакта сөйли. Шулай булмый ни, стоматология бүлекчәсе район үзәк шифаханәсе бүлекләре арасында һәрчак алдынгылар сафында булды бит: авырулар кабул итү саны, дәвалау дәрәҗәсе, шулай ук заманча җиһазланыш буенча да. Ә бу коллективка Рәшит Мостафин 1985 нче елдан җитәкчелек итә башлады. Шуннан соң бүгенге көнгә кадәрге чор - бүлекчәдә эшне камилләштерү буенча «удар» эшләгән елларга туры килә. Балаларда тешләр аномалиясен төзәтү буенча ортодонтия кабинеты үзе генә дә ни тора! Элегрәк мондый дефекты булган балаларны Казанга җибәрәләр иде. Табибта иң азы ун тапкыр булу таләп ителде. Үз башына төшкән кеше моның күпме чыгымнар таләп итүен белә булыр.

Теш уртларын дәвалый торган парадонтология кабинетының да район өчен әһәмияте бәяләп бетергесез зур. Хирургия, терапия, ортопедия, теш протезлау лабораториясе, балалар өчен кабинетлар булдыру, тешкә пломба куйганда заманча материал куллану, авыртуны баса торган чаралар, һ.б. яңалыкларның берсе генә дә бүлек мөдиренең якын катнашыннан башка гамәлгә кертелмәде. Коллективны да үзе туплады ул. 14 стоматолог, 5 теш табибы, 8 техниктан, 8 шәфкать туташыннан торган бу коллектив бер дигән эшкә сәләтле. Теш куйдыру, дәвалау, авыруларны профилактикалау кебек барлык чаралар да параллель рәвештә алып барыла, кабинетларда заманча җиһазлар да гел артуга бара. Стоматология хезмәткәрләре дә үз белемнәрен даими камилләштереп торалар. Әмма Рәшит Әбелгатович тынычлануны белә торган кешемени?! Медицина җиһазларын яңарту, теш протезлау өчен үз кою цехын булдыруны хәл итүне көтми торган бурыч саный ул. Киләчәктә дә тешләрне дәвалауда югары әйләнешле турбин аппаратуралар санын арттыруны беренче планга куя. Ни эшләмәк кирәк, дөнья булгач, гел уңай яклардан гына тормый инде, бер яхшының бер яманы табыла тора. Райпо рәисе урынбасары булып эшләгән хатыны Роза Хәбибулловна белән бик көйле, бер - берсен күз карашларыннан аңлап, тормышның ямен, рәхәтен татып яшәгәндә генә кешегә сөйләп аңлатып булмаслык нинди зур югалтуга дучар булды Рәшит Әбелгатович. Ярый ла шул вакытта янында улы - Ринаты булды. Дәвамчысы да, варисы да шул бит. Ата белән ул буларак кына түгел, хезмәттәшләр сыйфатында да фикерләре аерылмый аларның. Ринат Казан дәүләт медицина институтын тәмамлагач, ординатурада укыды, хәзер шул ук институтта ортопедик стоматология медицинасы кафедрасында ассистент булып эшли. Килене Лилия Казан инженер - төзелеш институтын тәмамлады, хәзер аспирантурада белем ала. Гаиләдә туп кебек үсеп килүче Булатка да 5 яшь инде.

Буын шулай дәвам итә. Шөкер, әле Мостафиннар нәселе чишмә башында торучылар Әбелгата ага белән Камәрия әби дә сау - сәламәтләр - Әлмәтнең үзендә яшәп яталар.

Әйе, гомер үтә. Әмма Рәшит Әбелгатовичның үзе әйтмешли, яшь артса да күңеле картаймый.

- Яшьлегемә кире кайта алсам, тормышны элеккегечә үк үтәр, язмышымны янәдән кабатлар идем,- ди ул - тормышны, үзенең плюслары һәм минуслары булган бу катлаулы замананы да булганынча кабул итеп, тәм, ямь табып яшим мин...

Тәм - ямь диюе Ринаты, Булаты, гомерлек юлдашы булган хезмәте, икенче туган җиренә әйләнгән Норлат җире, аның яхшылыкка яхшылык белән җавап бирүче халкы, гаилә тылы булган йорты, ихатасы янында үз куллары белән әвәрә килеп үстергән аллы - гөлле чәчәкләре, картаймыш көнендә тормыш дигән олы юлдан кулга - кул тотынып атлаучы Нурияседер инде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# ДАИга ярдәм итүче фонд

Билгеле булганча, ТР Министрлар Кабинеты Карарының 2 нче пункты нигезендә 1995 елда Октябрь районы эчке эшләр бүлегенең ДАИ бүлегендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгы фонды оешкан иде. Юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, юл хәрәкәте кагыйдәләрен пропагандалауга юнәлдерелгән чараларның нәтиҗәлелеген күтәрү безнең фондның бурычы булып тора. Фонд средстволары ТР Югары Советының махсус карары нигезендә каралган күләмдә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен кергән штрафлардан җыела (аларның 50 проценты ТР ДАИ идарәсе фондына күчерелә).

Фонд булдыру берничә юнәлештә эшне киң җәелдерүгә мөмкинлек бирде. Аеруча мәктәп һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә юл хәрәкәте кагыйдәләрен пропагандалауга зур игътибар бирелә. Бу максат өчен кагыйдәләрне өйрәнү буенча төрле чаралар - яшь инспекторлар, почмаклар конкурслары, сочинениеләр, спектакльләр конкурслары һәм тагын бик күп төрле мавыктыргыч чаралар үткәрелә. Алар ата - аналар, җәмәгатьчелекне балаларның юлда җәрәхәтләнү проблемасына, яшьтән үк аларны шәһәр урамнарында йөрү буенча белемнәрен һәм күнекмәләрен булдыруга игътибарларын җәлеп итүгә юнәлдерелә. Бу чаралар район мәгариф бүлеге белән берлектә үткәрелә. Нәкъ алар әлеге проблемаларны якыннан аңлыйлар да. Шунысы мөһим: балалар юл хәрәкәте кагыйдәләрен зур кызыксыну белән өйрәнәләр. Фонд чакыруы буенча Норлат балаларына кунакка юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнүгә багышланган «Ә син беләсеңме?» спектакле белән Бөгелмә драма театры килгәч тә мәктәп һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалар аны бик мавыгып карадылар.

Бары тик юл хәрәкәте кагыйдәләрен пропагандалау буенча чаралар үткәрүгә генә 20 млн.нан артык акча бүленде. Бүгенге көндә кагыйдәләр өйрәнү классына 8 млн. сумлык җиһазлар сатып алынды.

1997 елда ОСТО район Советы һәм безнең фонд каршында картинг - клуб ачылды. Клуб карамагында 5 картинг бар, киләчәктә тагын алырга уйлыйбыз. Ул әле эшен башлап кына килә, шуңа карамастан, егетләр зур кызыксыну белән транспорт белән идарә итү буенча башлангыч белемнәр алалар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен өйрәнәләр.

ДАИга юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итүгә, һәлакәтләрне киметүгә, ДАИның матди - техник базасын ныгытуга юнәлдерелгән ярдәм күрсәтү дә фонд вазифаларына керә. ДАИ машиналары рацияләр белән җиһазландырылды, бинага ремонт ясалды. Шулай ук кирәкле башка җайланмалар да, махсус чаралар һәм техника алына. Алар һичшиксез юлларда тәртип саклаучыларның эш күрсәткечләрен күтәрәчәк, ягъни юлларда һәлакәтләрне, шул исәптән балалар һәлакәтен дә киметәчәк.

**Г.ГЫЙМАЛЕТДИНОВА, ФБДД директоры.**

## ИРЛӘРГӘ ... ТУГРЫЛЫК ТАБЛЕТКАЛАРЫ

Гел сулга каеру гадәтенә күнеккән ирләр озакламый таблеткалар ярдәмендә җәмәгатьләренә тугрылык саклау мөмкинлеге алачак.

Бу таблетканы уйлап тапкан немец табиблары аның организм өчен зарасыз булуын ачыклаганнар. Ләкин үз хатыннарына гына карап торырга яратмаган ирләр бу таблетканы кулланудан баш тарталар икән.

## КҮКРӘКЛӘРЕ МУЛ ИКӘН

40 яшьләрдәге мул күкрәкле бер ханымны ир затыннан булган авиапассажирлар комсыз караш белән озатып калалар. Күпне күргән, күп гүзәлләрне сәфәргә озаткан аэропорт хезмәткәрләренең дә мондый калку күкрәкле хатынны күргәннәре булмаган.

Әмма бер таможня хезмәткәре бу ханымга үз һөнәре күзлеге аша караган һәм аны, махсус бүлмәгә чакырып, тентегән. Ханымның бер алагаем зур бюстгальтеры эчендә... бәләкәй генә күкрәкләре 6 зур, 65 нәни кәлтә еланнары арасыннан чак кына күренеп тора икән. Таможня хезмәткәре шулай итеп еланнар контрабандасы белән шөгыльләнүче җинаятьчене тоткан.

## ИРЛӘР «ГАРЕМ» ҮЗГӘРТӘ

Мичиган университеты галимнәре (АКШ) кызык ачыш ясаганнар: һәр ир кеше ел саен уртача дүрт хатынны үзләре белән җенси мөнәсәбәткә керергә мәҗбүр итәләр, ә хатыннар ике елга бер генә партнерларын үзгәртәләр икән.

5 меңгә якын кешедән сорау алганнан соң, шул ачыклана: һәр ир кеше танышып 5 көн үткәннән соң ук чираттагы хатын - кыз белән «йоклау» турында хыяллана, ә хатын - кыз танышып ярты ел үткәннән соң гына секс турында уйлана башлый. Матбугаттагы игъланнарны укып, ирләр сексуаль яктан күңел тартырлык хатын табу турында хыяллана, ә хатын - кызлар көчле, буйчан, иң мөһиме, тормышта таяныч булырлык партнер эзли.

# Орган - патша бүләге

Башкалабызга Голландиядән орган кайтарылуы хакында хәбәр иткән идек инде. Дөньякүләм танылган «Флектроп» фирмасы эшләгән 643 тонналы бу гаҗәеп уен коралы бик күпләрдә кызыксыну уятты. Күпме тора ул? Нинди акчага алынган?

Үткән елны, сайлаулар алдыннан, Россия Президенты Борис Ельцин Казанда Зур концерт залын - үзе әйткәнчә, Идел буендагы иң матур музыка сараен - ачуда катнашканда болай дигән иде: «Бервакыт минем яныма Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев килеп керде дә орган өчен акча алмыйча бу бүлмәдән чыкмыйм, диде...»

Президентыбызның мондый үҗәтлеге нәтиҗәсез калмады - 1 миллион доллардан да кыйммәтрәк торган орган Казанга кайтты. Орган осталары, бу өлкәдә 20 елдан артык тәҗрибәсе булган голландиялеләр Якоб Богат һәм Пауль Винкельмайер әйтүенчә, уен коралын өч айда җыеп бетерергә тырышачаклар.

II Бөтендөнья татар конгрессы көннәрендә башкалабыз искиткеч уен коралы - орган моңнарын ишетер дип өметләник.

**«Ватаным Татарстан»нан.**



20 нче, халык телендә ак кибет дип тә йөртәләр аны, ике дистә елга якын ул меңләгән халыкны ипи - сөте, кондитер товарлары һәм башкалары белән тукландырып тора. Хәзер, район кулланучылар җәмгыяте кырыс икътисади шартлар кичергәндә дә, кибет әле оптимизмын югалтмый: быелның яртыеллык планын алар 109 процентка үтәгәннәр. Димәк, халык элеккечә үк бу кибет баскычыннан еш күтәрелә. Биредә озак еллар райпо системасында эшләп тәҗрибә туплаган сатучылар Җәмилә Гыймалетдинова, Светлана Рассадина, Галина Бедова эшлиләр. Ә аларны тырыш хезмәткә өндәүче әйдәүче сатучы Галина Витальевна Перевезенцева 8 ел инде мөдир булып эшли. Кибетнең уңышында, халыкның бирегә яратып керүендә аларның һәркайсының өлеше зур.

**Рәсемдә: Г.Перевезенцева сатып алучыларны каршы ала.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

# «Окорочка»ны ничек пешерергә?

Иң башта тавык ботларын эретик. Аннары маринадлап - тоз һәм кызыл борыч, төелгән кинҗә орлыгы белән ышкыйк. Уңайлы савытка салып, өстенә су һәм лимон согы (3 : 2 күләмендә) бөркеп, түгәрәк кара борыч һәм алкалап туралган суган өстик. Сәгать ярым «пресс» астында тотып, бот итенә угыч аша чыгарылган сарымсак һәм кетчупны нечкә пычак очы белән төртеп чыгыйк. Бу эш күп вакытны да алмас, шул ук вакытта ризыкка аерым тәм дә бирер. Ә тиресе матур алсу төсле булсын дисәгез, өстенә сыек май сөртегез. Аннары ботларны табага тезеп өстенә аз гына су бөркеп газ миченә куегыз. 10 - 15 минут үткәч, табадагы шулпаны тавык өстенә сибегез. 30 - 35 минуттан, әйбәт кызган газ мичендә «окорочка» әзер булыр. Озак кыздырсагыз, ул катып китәргә мөмкин.



Ә тавыкны мичтән алгач, тозлы кыяр, пешерелгән кишер алкалары, яшелчәләр белән бизәгез.

# КРЕМЛЬ СЕРЛӘРЕ

«Бастырып чыгарырга ярамый»-большевикларның Кремльдәге чыгымнарын беренче тапкыр тикшергән яшерен комиссия документларына менә шундый резолюция салынган.

Россия. 1920 ел. Җимереклек, сугыш, завод һәм фабрикалар ябык, транспорт тик тора. Эшләүче кешеләргә шәһәрләрдә көнгә 400 әр грамм икмәк, айга дүрт сөрсегән селдь балыгы бирәләр. Хөкүмәт күчеп килгәннән соң Мәскәүдә бик тыгыз: подвалларда, элекке монастырьларда бер бүлмәдә 6-8 кеше яши. Бер генә гаилә булса, бәхет әле бу. Ә Кремльдә Кремльнең торак, азык-төлек, транспортка кагылышлы һәм башка тәртипләренә бәйле рәвештә партия эчендәге һәм партиясезләр арасындагы ризасызлык уңаеннан РКП (б) ның IX Бөтенроссия конференциясе яшерен төзегән комиссия эшли. Комиссия әгъзалары-уртача дәрәҗәдәге партияләләр ачыклаган хәлләр хәтта бүген дә тәэсир ясамыйча калмый.

Кремль ашханәләрендә иртәнге ашка 200 әр г ипи, 14г атланмай һәм шулкадәр уылдык, 25г сыр, 2 чәй кашыгы шикәр бирелә. Авыруларга өстәмә рәвештә 2 шәр йомырка һәм 200г ак ипи бирәләр. Төшке ашта түбәндәгеләр бирелә: 100г ит яки кыргый кош ите, балык-гарнир белән, 2 чәй кашыгы май, 100г ипи. Ә югары дәрәҗәле большевикларга 300г ит яки балык, өч тапкыр күбрәк гарнир һәм дүрт тапкыр күбрәк ипи тиеш була. Үзәк башкарма комитет ашханәсендә кичке ашны «дежурлар һәм физик эш белән шөгыльләнүчеләр»гә бирәләр (андыйлар көнгә 800 кеше җыела): бу-бер тәлинкә аш, 200г ипи.

Халык Комиссарлары Советы һәм Коминтерн ашханәләрендә түбәндәгечә тукланалар:

100г (сайлап) ит, сыр, ветчина, колбаса яки уылдык, 2 шәр йомырка, ярты кап сардина. Әлбәттә инде, майлы ипи.

Кичке аштан соң, гомуми тигезлек һәм бәхет җәмгыятен төзүчеләр үзләренең фатирларына таралалар. Троцкий хатыны һәм ике баласы белән биш бүлмә били; Калинин әнисе, хатыны һәм өч баласы белән биш бүлмә; Ганецкий хатыны, ике баласы, хезмәтчесе һәм тәрбиячесе белән биш бүлмә биләп тора. Шунысын да әйтергә кирәк, бүлмәләр 9ар, 12 шәр метрлы гына түгел, ә 30 ар метрлы һәм хәтта зуррак та булган. Барысының да диярлек хезмәтчеләре, бала караучылары була. Ә ишегалдын җыештыручылар, каравылчылар, курьерлар юеш, сасы, яшәү өчен көйләнмәгән үтә кысан подвалларда яшиләр.

Кремльнең үз автобазасы да була. Зиновьев, Бухарин, Сталин чынлыкта аның хезмәтеннән файдаланмыйлар. Ленин казна машинасында уртача 25 әр километр, ә менә аның сеңелесе Мария Ильинична-47 шәр, Луначарский 93 әр чакрым юл йөри. Автобаза җитәкчеләре дә үзләрен онытмыйлар: башлык белән комиссарның берәр машинасы була.

Комиссия үзенең тикшерү нәтиҗәләрен 1921 елның мартында РКП(б) ның X съездында игълан итәргә тырышып карый, ләкин Политбюро бу документ белән Үзәк Комитеттан бик аз кешене генә таныштырырга карар кыла. Документка: «Бастырып чыгарырга ярамый», дигән билге куела.

**«Российская газета»дан.**

## Сатабыз




**1988 елда чыккан СК-5 «Нива» бөртек җыю комбайны.** Тел.: 5-22-81.

***

**ВАЗ-21061, «Опель» машиналары, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-18-81.

***

**Фрунзе урамында янәшә 2 йорт, 10 сутый бакчасы, мунчасы, гаражы, базы белән сарае, коесы бар, газ үткәрелгән. Бәясе-35 млн. сум**. Тел.: 5-14-92.

***

**Шәһәр уртасында хосусыйлаштырылган 1 бүлмәле фатир. Сарае бар.** Тел.: 5-40-88.

***

**Шифер һәм керамзит-бетон блоклар, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-21-22.

***

**1 бүлмәле фатир (шикәр заводы микрорайонында 2 катта).** Адрес: Циолковский урамы, 11-95.

***

**Йорт. Гараж, мунча, йорт яны корылмалары, су, үзәктән һәм мичтән җылытыла**. Адрес: Тукай ур., 23.

***

**1994 елгы ВАЗ-2106.** Адрес: Лермонтов ур., 37.

***

**Ашыгыч төстә кухня гарнитурлары (2650), «SONJ», «PANASONIK» (650) тумбалары, одеал комплектлары (255), барысы да Германиядә эшләнгән, кыйммәт түгел.** Тел.: 5-17-79 ( кич белән). 20659 номерлы таныклык.

***

**1979 елгы ВАЗ-2103.** Югары Норлатта Мөхәммәтов Зәйдуллага мөрәҗәгать итәргә.

***

**Капиталь йорт-усадьба.** Вишневая Поляна авылында Кашицын Сергейга мөрәҗәгать итәргә.

***

**1,25 х 2,5 метрлы цинкланган түбә калае, 70 мең.** Тел.: 2-13-69.

***

**11 х 5,5 метрлы өй бурасы.** Завод тыкрыгы 2 - 16 адресы буенча 18.00 сәг. тән соң мөрәҗәгать итәргә.


## Компьютер ияләре игътибарына!

***Карл Маркс ур., 51 «а» адресы буенча урнашкан «ЭКСПРЕСС - ФОТО» фотосалонында ЭВМга чыгым материаллары сату бүлеге ачылды. Сатуда NDD, FDD, mouse, keyboard, SUGA видеоплаталары, тавыш платалары, актив дисковод колонкалары, джойстиклар, принтерлар һәм ксероксларга картриджлар, CANON өчен тонер, дискетлар, буяучы тасмалар, монитор өчен саклау фильтлары, саклаулы компьютер өчлекләре, CDда уен һәм уку - танып - белү программасы, уку һәм махсус әдәбият һ.б. бар.***

***Фотосалонда әйдәп баручы җитештерүче фирмалар фототасмалары, фотоаппаратлар, фотоальбомнар һәм башка кирәк - яраклар бар. «ЭКСПРЕСС - ФОТО»дан алынган тасмалар бушлай ачыгайтыла. Лицензия номеры - А - 96 118585. Эш вакыты - 9.00дан 18.00га кадәр, төшке ял - 13.00дән - 14.00гә кадәр.***

## Идел Буе региональ наркология үзәге

***Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.***

***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, 1, 15 августта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә. Заказ N 7201